Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең
Бикәсаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

22 ноябрь 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Бикәсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 99 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 53 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикасаз авылында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Бикәсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү?»» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Бикәсаз авылы, Мәктәп урамы, 1А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гыйниятуллина